| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 31 март № 200

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 ел, 27 август, 616 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 ел, 27 август, 616 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең барлык тексты буенча тиешле килешләрдәге «Эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» сүзләренә алыштырырга;

1.3 нче пунктта:

алтынчы абзацтагы «төзелгән» сүзе алдыннан «федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сәнәгать (индустриаль) паркы - паркның бердәм операторы (идарә итүче компания) тарафыннан идарә ителүче күчемсез мөлкәт объектлары (кимендә 80 мең кв.метр мәйданлы җир кишәрлеге (кишәрлекләре), административ, җитештерү, склад урыннары һәм сәнәгать (индустриаль) паркы эшчәнлеген тәэмин итүче башка

урыннар) һәм кече һәм урта җитештерүләрнең нәтиҗәле эшләве өчен шартлар тудыруга һәм аларны компактлы урнаштыруга ярдәм итә торган инфраструктура комплексы;»;

түбәндәге эчтәлекле унынчы яңа абзац өстәргә:

«төзелә (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркы - паркның бердәм операторы (идарә итүче компания) тарафыннан идарә ителүче күчемсез мөлкәт объектлары (кимендә 80 мең кв.метр мәйданлы җир кишәрлеге (кишәрлекләре), төзелә яки проектлана торган (эксплуатациягә кертелмәгән) административ, җитештерү, склад урыннары һәм сәнәгать (индустриаль) паркы эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән башка урыннар) һәм кече һәм урта җитештерүләрнең нәтиҗәле эшләве өчен шартлар тудыруга һәм аларны компактлы урнаштыруга ярдәм итүче төзелә яки проектлана торган (эксплуатациягә кертелмәгән) инфраструктура комплексы;»;

унынчы – егерме икенче абзацларны тиешенчә унберенче – егерме өченче абзацлар дип санарга;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы (алга таба – сәнәгать мәйданчыгы) - бердәм оператор (идарә итүче компания) тарафыннан идарә ителүче, кимендә 20 мең кв.метр мәйданлы җир кишәрлегендә урнашкан, бердәм чиге булган һәм аның эчендә яңа җитештерүләр булдыру һәм үстерү өчен уңай шартлар тудырыла торган барлык милек рәвешендәге күчемсез мөлкәт объектларының территориаль аерымланган комплексы;»;

түбәндәге эчтәлекле унөченче яңа абзац өстәргә:

«төзелә (проектлана) торган муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы (алга таба – төзелә (проектлана) торган сәнәгать мәйданчыгы) - бердәм оператор (идарә итүче компания) тарафыннан идарә ителүче, кимендә 20 мең кв.метр мәйданлы җир кишәрлегендә урнашкан, бердәм чиге булган, аның эчендә төзелүче яки проектланучы (эксплуатациягә кертелмәгән) яңа җитештерүләр булдыру һәм үстерү өчен уңай шартлар тудырыла торган барлык милек рәвешендәге күчемсез мөлкәт объектларының территориаль аерымланган комплексы;»;

унөченче – егерме өченче абзацларны тиешенчә ундүртенче – егерме дүртенче абзацлар дип санарга;

2.1 нче пунктта:

өченче абзацтагы «сәнәгать» сүзеннән соң «(индустриаль)» сүзен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«резидентлар тарафыннан алып бару турында төзелгән килешүләр, ә «булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркы», «булдырыла (проектлана) торган сәнәгать мәйданчыгы» төре аккредитациясен алуга дәгъва итүче гариза бирүчеләр өчен – шул исәптән түбәндәге күрсәткечләргә ирешү бурычларын күздә тота торган кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы объекты территориясендә резидентларның эшчәнлек алып бару ниятләре турында төзелгән килешүләр:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«шәхси сәнәгать (индустриаль) паркларын аккредитацияләүгә дәгъва итүче гариза бирүчеләр өчен – бу Тәртипкә теркәлгән 5 нче кушымта нигезендә шәхси сәнәгать (индустриаль) паркы эшчәнлеге күрсәткечләренең мәгънәләре турында мәгълүматлар;

«сәнәгать мәйданчыгы» төре буенча аккредитация алуга дәгъва итүче гариза бирүчеләр өчен – бу Тәртипкә теркәлгән 6 нчы кушымта нигезендә сәнәгать мәйданчыгы эшчәнлеге күрсәткечләренең мәгънәләре турында мәгълүматлар;»;

2.4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Гариза бирүченең фактта урнашкан урыны Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәгенең җаваплы хезмәткәре тарафыннан гаризада күрсәтелгән факттагы адрес буенча барып тикшерелә.

Гаризаны тикшерү йомгаклары буенча Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге гаризаны аккредитациягә кертү яки гаризаның бу Тәртип таләпләренә туры килмәве хакында бәяләмә төзи.

Гариза бирүченең гаризада күрсәтелгән факттагы адрес буенча булмавы гаризаны аккредитациягә кертүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Бәяләмәгә Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге җитәкчесе кул куя.»;

2.5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бу Тәртипнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән, аккредитация алу өчен кирәк булган документларны кертмәү йә бу документларны тулы булмаган күләмдә кертү гаризаны аккредитациягә кертүдән баш тарту өчен нигез булып тора.»;

2.7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Барып тикшерү йомгаклары буенча гаризада күрсәтелгән факттагы адресның гариза бирүче фактта урнашкан урынга туры килүен һәм гаризаның бу Тәртип таләпләренә туры килү-килмәвен анализлау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге аккредитацияләргә рөхсәт иткән гаризалар комиссия утырышында гариза бирүченең җитәкчесе йә законнарга таянып рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә аның вәкиле катнашында карала.»;

2.9 нчы пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча аккредитацияләү турында таныклык биреп, аккредитация бирелә торган гариза бирүчеләрне билгеләү хакында. Аккредитацияләү турында таныклык комиссия утырышы үткәрелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бирелә.»;

2.10 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Гариза бирүченең бу Тәртипнең 3 бүлегендә күрсәтелгән кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектлары эшчәнлегенә карата куела торган таләпләргә туры килмәве гариза бирүчене аккредитацияләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.»;

3.2 нче һәм 3.2.1 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. «Сәнәгать (индустриаль) паркы», «булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркы» төренә кертелгән аккредитацияне гариза бирүче түбәндәге таләпләр (критерийлар) үтәлгәндә алырга мөмкин:

3.2.1. Сәнәгать (индустриаль) паркының, булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркының күчемсез мөлкәт объектлары комплексы белән идарә итү, шулай ук аның оештыру эшчәнлеге идарә итүче компания тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3.2.2 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.2. Сәнәгать (индустриаль) паркы күрсәтә торган төп хезмәтләр:»;

3.2.3 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.3. Шәхси сәнәгать (индустриаль) паркларын аккредитацияләүгә дәгъва итүче гариза бирүчеләр өчен эшләп торучы шәхси сәнәгать (индустриаль) паркы чагыштырма күрсәткечләренең минималь мәгънәләренә туры килү зарур (1 нче таблица):»;

3.2.4 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.4. Сәнәгать (индустриаль) паркының, булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркының җир кишәрлеге түбәндәге мәҗбүри таләпләргә туры килергә тиеш:»;

3.2.5 нче пунктның бишенче, алтынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өстәмә рәвештә гариза бирүче, шул исәптән «булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркы» төрен аккредитацияләүгә дәгъва итүче, түбәндәге критерийны раслый торган документ кертергә хокуклы:

рөхсәт ителгән файдалану төре сәнәгать (индустриаль) паркының, булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркының белдерелгән максатларына туры килү.»;

3.2.5 нче пункттагы «индустриаль (сәнәгать)» сүзләрен «сәнәгать (индустриаль)» сүзләренә алыштырырга, «паркы» сүзе алдына «булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 3.2.6.1 нче пункт өстәргә:

«3.2.6.1. Булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркына транспорт белән баруга карата мәҗбүри таләпләр:

булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркы чигенә кадәр салынган федераль, төбәк яки җирле әһәмияттәге юлга тоташа торган юл булу;

төзелеш техникасы керүне һәм инженерлык эзләнүләрен үткәрүне тәэмин итәргә ярдәм итә торган җир кишәрлегенә юлдан транспорт төшү урыны булу.

Гариза бирүче түбәндәге критерийларны раслый торган документларны өстәмә рәвештә бирергә хокуклы:

төбәк юлларының якын булуын (1 – 2 км);

федераль магистральләрнең якын булуын (1 – 5 км);

эшләп торучы төяп җибәрү-бушату станциясенең эшләп торучы тимер юл тармагына якын булуын (станциягә кадәр 1 – 2 км);

булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркы чикләренә якын һәм (яки) булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркы территориясе буйлап үтә торган аерым тимер юл тармагы булуны;

якындагы торак пунктлар белән транспорт элемтәсе (үз вакытында йөреп торучы җәмәгать транспорт) булуны;

аэропорт якын булуны (20 – 30 км).»;

түбәндәге эчтәлекле 3.2.7.1 нче пункт өстәргә:

«3.2.7.1. Булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркы инженерлык инфраструктурасы мәҗбүри критерийлары:

электр челтәрләренә технологик тоташтыру өчен булган яки эшләнә торган техник шартлар;

газ белән тәэмин итү һәм/яки җылылык белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру өчен булган яки эшләнә торган техник шартлар;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системасына тоташтыру өчен булган яки эшләнә торган техник шартлар.

Гариза бирүче түбәндәге критерийларны раслый торган документларны өстәмә рәвештә кертергә хокуклы:

булдырыла (проектлана) торган сәнәгать (индустриаль) паркы территориясендә кимендә 2 МВт ирекле куәт белән тәэмин ителгән электр челтәрләренә тоташтыру ноктасы булуны;

газ белән тәэмин итү һәм җылылык белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтырылган булуны;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системасына тоташтырылган булуны;

чистарту корылмалары булуны.»;

3.4 нче һәм 3.4.1 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. «Сәнәгать мәйданчыгы», «булдырыла (проектлана) торган сәнәгать мәйданчыгы» төренә кертелгән аккредитация гариза бирүче тарафыннан түбәндәге таләпләр (критерийлар) үтәлгәндә алынырга мөмкин:

3.4.1. Сәнәгать мәйданчыгының, булдырыла торган сәнәгать мәйданчыгының күчемсез мөлкәт объектлары комплексы белән идарә итү, шулай ук аның оештыру эшчәнлеге идарә итүче компания тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3.4.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.4. Сәнәгать мәйданчыгының, булдырыла (проектлана) торган сәнәгать мәйданчыгының җир кишәрлеге түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:»;

3.4.5 нче пункттагы «сәнәгать мәйданчыгының» сүзләре алдына «булдырыла (проектлана) торган» сүзләрен өстәргә;

3.4.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.6. Сәнәгать мәйданчыгына транспорт белән баруга карата мәҗбүри таләпләр:

сәнәгать мәйданчыгы чигенә кадәр эксплуатациягә кертелгән каты өслекле юллар булу;

юл җирле, төбәк яки федераль трассаларга тоташкан булу.

Гариза бирүче түбәндәге критерийларны раслый торган документларны өстәмә рәвештә кертергә хокуклы:

төбәк юлларының якын булуын (1 – 2 км);

федераль магистральләрнең якын булуын (1 – 5 км);

эшләп торучы тимер юл тармагының эшләп торучы төяп җибәрү-бушату станциясенә якын булуын (станциягә кадәр 1 – 2 км);

якындагы торак пунктлар белән транспорт элемтәсе (үз вакытында йөреп торучы җәмәгать транспорты) булуны;

аэропортның якын булуын (5 – 15 км).»;

түбәндәге эчтәлекле 3.4.6.1 нче пункт өстәргә:

«3.4.6.1. Булдырыла (проектлана) торган сәнәгать мәйданчыгына транспорт белән баруга карата мәҗбүри таләпләр:

булдырыла (проектлана) торган сәнәгать мәйданчыгы чигенә кадәр салынган федераль, төбәк яки җирле әһәмияттәге юлларга тоташкан юллар булу;

төзелеш техникасы керүне һәм инженерлык эзләнүләрен үткәрүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган җир кишәрлегенә юлдан транспорт төшү урыны булу.

Гариза бирүче бу Тәртипнең 3.4.6 нчы пунктындагы бишенче – тугызынчы абзацларда күрсәтелгән критерийларны раслый торган документларны өстәмә рәвештә кертергә хокуклы.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.4.7 нче пункт өстәргә:

«3.4.7. Сәнәгать мәйданчыгы инженерлык инфраструктурасының мәҗбүри критерийлары түбәндәгеләр:

сәнәгать мәйданчыгы территориясендә кимендә 0,8 МВт ирекле куәт белән тәэмин ителгән электр челтәрләренә тоташтыру нокталары булу;

газ белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру өчен булган яки эшләнә торган техник шартлар һәм/яки җылылык белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру өчен булган яки эшләнә торган техник шартлар булу;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системасына тоташтыру өчен булган тоташу яки эшләнә торган техник шартлар булу.

Гариза бирүче өстәмә рәвештә чистарту корылмалары булуны раслый торган документлар кертергә хокуклы.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.4.7.1 нче пункт өстәргә:

«3.4.7.1. Булдырыла (проектлана) торган сәнәгать мәйданчыгы инженерлык инфраструктурасының мәҗбүри критерийлары түбәндәгеләр:

электр челтәрләренә технологик тоташтыру өчен булган яки эшләнә торган техник шартлар;

газ белән тәэмин итү һәм/яки җылылык белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру өчен булган яки эшләнә торган техник шартлар;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системасына тоташтыру өчен булган яки эшләнә торган техник шартлар.

Гариза бирүче булдырыла (проектлана) торган сәнәгать мәйданчыгы территориясендә кимендә 0,8 МВт ирекле куәт белән тәэмин ителгән электр челтәрләренә тоташтыру ноктасы булуны раслый торган документларны өстәмә рәвештә кертергә хокуклы.»;

Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле 5 нче һәм 6 нчы кушымталар өстәргә:

«Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибенә 5 нче кушымта

Форма

Шәхси сәнәгать (индустриаль) паркы эшчәнлеге күрсәткечләренең мәгънәләре

| **Күрсәткечнең исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **Мәгънәсе** |
|---|---|---|
| Шәхси сәнәгать (индустриаль) паркының җир кишәрлеге мәйданы | кв.метр | |
| Шәхси сәнәгать (индустриаль) паркы урыннары мәйданы | кв.метр | |
| Шәхси сәнәгать (индустриаль) паркы резидентлары – эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан булдырылган эш урыннары саны | берәмлек | |
| Шәхси сәнәгать (индустриаль) паркында урнаштыру турында килешү төзелгән вакыттан шәхси сәнәгать паркы резидентлары тарафыннан төп фондларга кертелгән инвестицияләр күләме | мең сум (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) | |
| Җитештерүнең проектлау куәтенә чыкканда паркта урнаштыру турында килешүләр төзегән шәхси сәнәгать (индустриаль) паркы резидентлары кулга алган еллык акча | мең сум (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) | |
| Шәхси сәнәгать (индустриаль) паркы резидентларына бирелгән (арендага яки милеккә) җир кишәрлекләре мәйданы | кв.метр | |
| Шәхси сәнәгать (индустриаль) паркы резидентларына бирелгән (арендага яки милеккә) урыннар мәйданы | кв.метр | |
| Шәхси сәнәгать (индустриаль) паркы территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешү төзегән резидентлар саны | берәмлек | |

М.У.____________________ ;

(җитәкче имзасы)

«Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибенә 6 нчы кушымта

Форма

Сәнәгать мәйданчыгы эшчәнлеге күрсәткечләре мәгънәләре

| **Күрсәткеч исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **Мәгънәсе** |
|---|---|---|
| Сәнәгать мәйданчыгының җир кишәрлеге мәйданы | кв.метр | |
| Сәнәгать мәйданчыгы урыннары мәйданы | кв.метр | |
| Сәнәгать мәйданчыгы резидентлары – эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан булдырылган эш урыннары саны | берәмлек | |
| Сәнәгать мәйданчыгы территориясендә урнаштыру турында килешү төзелгән вакыттан сәнәгать мәйданчыгы резидентлары тарафыннан төп фондларга гамәлгә ашырылган инвестицияләр күләме | мең сум (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) | |
| Җитештерүнең проектлау куәтенә чыкканда сәнәгать мәйданчыгы территориясендә урнаштыру турында килешүләр төзегән сәнәгать мәйданчыгы резидентлары кулга алган еллык акча | мең сум (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) | |
| Сәнәгать мәйданчыгы резидентларына бирелгән (арендага яки милеккә) җир кишәрлекләре мәйданы | кв.метр | |
| Сәнәгать (индустриаль) мәйданчыгы резидентларына бирелгән (арендага яки милеккә) урыннар мәйданы | кв.метр | |
| Сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешү төзегән резидентлар саны | берәмлек | |

М.У.____________________ ».

(җитәкче имзасы)

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\200.doc